**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 25 февралендәге 533 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 6 апрелендәге 1724 номерлы «Казан шәһәре территориясендә стационар булмаган сезонлы сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемаларын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль законнар, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 21 августындагы 7575 номерлы «Казан шәһәре территориясендә стационар булмаган сезонлы сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 6 апрелендәге 1724 номерлы «Казан шәһәре территориясендә стационар булмаган сезонлы сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемаларын раслау турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 14 февралендәге 340, 2017 елның 10 маендагы 1681, 2017 елның 5 июнендәге 2093, 2017 елның 15 июнендәге 2184, 2017 елның 17 июлендәге 2651, 2017 елның 29 ноябрендәге 4884, 2018 елның 5 февралендәге 481, 2018 елның 11 сентябрендәге 4859, 2018 елның 2 ноябрендәге 5666, 2019 елның 28 мартындагы 1011, 2019 елның 5 июнендәге 2057, 2020 елның 7 маендагы 1308, 2020 елның 29 июлендәге 2057, 2020 елның 29 октябрендәге 3051, 2021 елның 16 апрелендәге 913, 2021 елның 22 июнендәге 1546, 2021 елның 3 сентябрендәге 2196, 2021 елның 22 сентябрендәге 2379, 2021 елның 22 сентябрендәге 2402, 2022 елның 25 маендагы 1520, 2022 елның 11 августындагы 2696, 2023 елның 28 июлендәге 2136, 2023 елның 29 августындагы 2457, 2024 елның 27 апрелендәге 1687, 2024 елның 29 ноябрендәге 4944, 2025 елның 15 маендагы

1509 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» МБУ тарафыннан җир кишәрлекләреннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында тапшырылган парклар һәм скверлар территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы» дип аталучы 9 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Крылья Советов паркы» бүлегенә түбәндәге эчтәлектәге юл өстәргә:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны. Профиле** | **Мәйданы, кв.м** |
| --- | --- | --- |
| «Ф-ПС-9 | Фотохезмәтләр күрсәтү объектын урнаштыру | 2 гә кадәр» |

1.2. «Зәңгәр күлләр янындагы территория» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны. Профиле** | **Мәйданы, кв.м** |
| --- | --- | --- |
| «АС-ПС-12 | Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү аппаратын (вендинг) урнаштыру | 1 гә кадәр |
| Ф-ПС-15 | Фотохезмәтләр күрсәтү объектын урнаштыру | 2 гә кадәр» |

1.3. «Җиңү паркы» бүлегендә МО-ПС-15 юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны. Профиле** | **Мәйданы, кв.м** |
| --- | --- | --- |
| «МО-ПС-15 | Мобиль объектны урнаштыру | 15 кә кадәр» |

1.4. «“Казан” гаилә үзәге янындагы парк» бүлегендә:

1.4.1. СК-ПС-24 юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны. Профиле** | **Мәйданы, кв.м** |
| --- | --- | --- |
| «СК-ПС-24 | Сезонлы стационар булмаган кафе урнаштыру | 40 ка кадәр» |

1.4.2. түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| Реестр номеры | Адресы, урнашу урыны. Профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|
| «Ф-ПС-10 | Фотохезмәтләр күрсәтү объектын урнаштыру | 2 гә кадәр» |

1.5. «Казан шәһәренең Үзәк мәдәният һәм ял паркы» бүлегендәге М-ПС-2 юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| Реестр номеры | Адресы, урнашу урыны. Профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|
| «М-ПС-2 | Туңдырма сату буенча сезонлы сәүдә ноктасын урнаштыру | 10 га кадәр» |

1.6. «"Черек күл" паркы» бүлегендә:

1.6.1. М-ПС-8 юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| Реестр номеры | Адресы, урнашу урыны. Профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|
| «МВ-ПС-11 | Тарага салынган туңдырма, тәм-томнар һәм салкынча эчемлекләр сату буенча сезонлы сәүдә ноктасын урнаштыру | 6 га кадәр» |

1.6.2. түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| Реестр номеры | Адресы, урнашу урыны. Профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|
| «ЛВ-ПС-3 | Стационар җәмәгать туклану объекты янында сезонлы кафе урнаштыру | 35 кә кадәр» |
| ЛВ-ПС-4 | Стационар җәмәгать туклану объекты янында сезонлы кафе урнаштыру | 200 гә кадәр» |

1.7. «Тинчурин скверы» бүлегендә М-ПС-3 юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| Реестр номеры | Адресы, урнашу урыны. Профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|
| «М-ПС-3 | Туңдырма сату буенча сезонлы сәүдә ноктасын урнаштыру | 6 га кадәр» |

1.8. «Кабан күле яр буе (М.Сәлимҗанов һәм Татарстан урамнары ягыннан)» бүлегендә түбәндәге эчтәлекле юлны төшереп калдырырга:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны. Профиле** | **Мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|
| «ЛВН-ПС-2 | Һ.Такташ урамында, 58 йорт янында стационар булмаган җәмәгать туклануы объектында сезонлы кафе урнаштыру | 200 гә кадәр» |

1.9. «“Елмай” балалар паркы» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны. Профиле** | **Мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|
| «АБ-ПС-4 | Хезмәт күрсәтә торган сезонлы объект (аттракционнар) урнаштыру | 200 гә кадәр |
| Ф-ПС-11 | Фотохезмәтләр күрсәтү объектын урнаштыру | 2 гә кадәр» |

1.10. Вахитов районына караган өлештә түбәндәге эчтәлекле «Фукс бакчасы» дигән яңа бүлек өстәргә:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны. Профиле** | **Мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|
| **«Фукс бакчасы** | | |
| Ф-ПС-14 | фотохезмәтләр күрсәтү объектын урнаштыру | 2 гә кадәр» |

1.11. «Урицкий паркы» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| **Реестр номеры** | **Адресы, урнашу урыны. Профиле** | **Мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|
| «Ф-ПС-12 | Фотохезмәтләр күрсәтү объектын урнаштыру | 2 гә кадәр» |

1.12. «“Фестивальный” бульвары» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| Реестр номеры | Адресы, урнашу урыны. Профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|
| «Ф-ПС-13 | Фотохезмәтләр күрсәтү объектын урнаштыру | 2 гә кадәр» |

1.13. «Татарстан Республикасында төзелеш тармагы барлыкка килүнең 100 еллыгы скверы» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| Реестр номеры | Адресы, урнашу урыны. Профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|
| «СР-ПС-6 | Сезонлы спорт-күңел ачу объектын урнаштыру | 50 гә кадәр» |

1.14. «Весна торак комплексы» бүлегендә М-ПС-9 юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

| Реестр номеры | Адресы, урнашу урыны. Профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|
| «М-ПС-9 | Туңдырма сату буенча сезонлы сәүдә ноктасын урнаштыру | 6 га кадәр» |

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**